ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2025ел.

№ 10220

Башкарма комитетның «Муниципаль яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 562 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 22 сентябрендәге 720 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 562 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2025 елның 2 июнендәге 3959 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) муниципаль яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

- 6-9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Яшьләр сәясәте оешмаларында физик культура хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Хореограф | 26 610 |

7. Яшьләр сәясәте оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту бүлеге секретаре | 25 960 |
| Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Режим буенча дежур | 26 090 |
| | Кече тәрбияче | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | 27 390 |
| | Физик культура буенча инструктор | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Концертмейстер | 27 500 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | 27 650 |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Тәрбияче | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Педагог-психолог | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | 27 780 |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| | Өлкән тәрбияче | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |

| | | |
|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-производство) мастерское һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыручы башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | 27 830 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 27 890 |

«Яшьләр белән эшләү буенча белгеч» һәм «яшьләр белән социаль эш буенча белгеч» вазыйфаларын биләгән хезмәткәрләрнең база оклады 27 500 сум тәшкил итә.

8. Яшьләр сәясәте оешмалары медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета буенча шәфкать туташы (диета буенча медбрат) | 27 210 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медбрат) | 27 760 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медбрат) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 32 090 |

Яшьләр сәясәте оешмаларының медицина хезмәткәрләре өчен база окладына тармакның өстенлекле коэффициенты кулланыла. Тармакның өстенлекле коэффициентының күләме 1,1 тәшкил итә.

Күрсәтелгән коэффициентны база окладына карата куллану яңа база окладының барлыкка китерә һәм компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләгәндә исәпкә алына.

9. Яшьләр сәясәте оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең база оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билет контролеры | 26 900 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 27 450 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | |
| Мәдәни чаралар оештыручы | |
| Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 28 000 |
| Тавыш операторы | |
| Кинооператор | |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар редакторы | |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | |
| Яктылык буенча рәссам | |
| Рәссам-декоратор | |
| Рәссам-бизәүче | |
| Рәссам-фотограф | |

| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый учреждениеләрнең һәм оешмаларның бүлек (сектор) мөдире | 29 320 |
| Тавыш режиссеры | |
| Режиссер-сәхнәгә куючы | |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | |
| Сәнгать җитәкчесе | |

Яшьләр сәясәте оешмаларының мәдәният хезмәткәрләре өчен база окладына карата тармакның өстенлекле коэффициенты кулланыла.

Тармакның өстенлекле коэффициентының күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

«Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме буенча - 1.05;

«Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һәм «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәре буенча - 1,12;

«Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме буенча - 1,25.

Әлеге коэффициентларны база окладына карата куллану яңа база оклады барлыкка китерә һәм компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләнгәндә исәпкә алына.»;

- 29 пунктта 16 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 нчы таблица

Яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең база окладлары күләме

| № т/б | Оешма тибының исеме / оешманың штат саны, берәмлек | Хезмәткә түләү төркеме | Җитәкченең база оклады <*> , сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Яшьләр үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (аны да кертеп) | 1 | 38 720 |
| | 11 дән 30 га кадәр (аны да кертеп) | 2 | 43 200 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (аны да кертеп) | 3 | 48 640 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (аны да кертеп) | 4 | 51 910 |
| | 71 дән 150 гә кадәр (аны да кертеп) | 5 | 54 090 |
| | 151 дән | 6 | 60 740 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары | | |
| | 12 гә кадәр (аны да кертеп) | 1 | 38 720 |
| | 13 тән 25 кә кадәр (аны да кертеп) | 2 | 44 170 |
| | 26 дан 40 ка кадәр (аны да кертеп) | 3 | 49 730 |
| | 41 дән 70 кә кадәр (аны да кертеп) | 4 | 51 910 |
| | 71 дән 140 ка кадәр (аны да кертеп) | 5 | 55 300 |
| | 141 дән | 6 | 80 470 |
| 3. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (аны да кертеп) | 1 | 40 540 |
| | 11 дән 30 га кадәр (аны да кертеп) | 2 | 46 460 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (аны да кертеп) | 3 | 47 670 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (аны да кертеп) | 4 | 48 880 |
| | 71 дән 90 га кадәр (аны да кертеп) | 5 | 50 090 |
| | 91 дән | 6 | 51 300 |
| 4. | Студентларның хезмәт отрядлары үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (аны да кертеп) | 1 | 47 430 |
| | 11 дән 30 га кадәр (аны да кертеп) | 2 | 48 640 |
| | 31 дән | 3 | 49 850 |
| 5. | Балаларга һәм яшьләргә психологик- педагогик ярдәм үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (аны да кертеп) | 1 | 48 520 |
| | 11 дән 25 кә кадәр (аны да кертеп) | 2 | 52 150 |
| | 26 дан | 3 | 55 780 |
| 6. | Балалар һәм яшьләр өчен телефон аша ашыгыч психологик ярдәм үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (аны да кертеп) | 1 | 47 190 |
| | 11 дән 30 га кадәр (аны да кертеп) | 2 | 52 030 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (аны да кертеп) | 3 | 56 870 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (аны да кертеп) | 4 | 61 710 |
| | 71 дән | 5 | 67 760 |

--------------------------------

<*> Муниципаль яшьләр сәясәте оешмаларының җитәкчеләре өчен башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм мөһимлеген исәпкә алып, шулай ук муенициаль яшьләр сәясәте оешмаларына эшчәнлек профиле буенча оештыру һәм методик ярдәм күрсәтүгә бәйле рәвештә, база окладына карата 1,1 күләмендә арттыру коэффициенты билгеләнә.»;

2) муниципаль яшьләр сәясәте оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

- 4, 5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Яшьләр сәясәте оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 010 |

5. Яшьләр сәясәте оешмаларының җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |

| | |
|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 26 660 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 26 870 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 27 080 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 27 300 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 27 560 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 780 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 28 000 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 29 040 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 29 260 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 29 480»; |

- түбәндәге эчтәлектә 5.1 һәм 5.2 пунктлар өстәргә:

«5.1. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

5.2. Берьюлы ике урында, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә башкарылган эшләр күләменә бәйле рәвештә башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы ике урында эшләү тәртибендә билгәгән вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмен билгеләү һәр вазыйфа өчен аерым башкарыла.».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ